

Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Яңа көн


Октябрь 2019 № 2

*Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар! Менә инде уку елының икенче аена аяк бастык. Бу айда бәйрәмнәр бик күп. 1 октябрь - өлкәннәр көне, 5 октябрь - укытучылар көне. Без чын күңелдән укытучы абый-апаларыбызны шушы матур бәйрәм белән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхетле озын гомер, җан тынычлыгы телибез!*

## Бу санда

Укытучылар бәйрәме котлы булсын!


Хөрмәтле укытучыларыбыз! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез – Укытучы көне белән котлыйбыз! Бүгенге истәлекле көндә барлык укытучыларга рәхмәт сүзләре белдерәсе һәм хөрмәт күрсәтәсе килә. Сезнең профессиональ, игътибарлы, таләпчән булуыгыз һәм күңел җылыгыз безнең сәләтләрне һәм талантларны ачарга ярдәм итә. Әлбәттә, укытучы хезмәте беркайчан да җиңел булмады, бүген ул тагын да катлаулырак. Укытучы эше зур түземлелек, даими камилләшү таләп итә. Укытучы – ул һөнәр генә түгел, укытучы булып туарга кирәк! Мәктәптә үткәргән һәр көнегез балалар белән аралашудан шатлык китерсен! Укучылар үз белемнәре белән куандырсын, ә мәктәпне тәмамлаучылар туган мәктәпләрен һәм яраткан укытучыларын онытмасын! Бу сезнең хезмәтегез өчен иң югары бәя!



Бәйрәм белән Сезне, укытучым!
Йөрәгемнең якын кешесе.
Дөнья серен миңа өйрәтүчем.
Яшь җаннарга — Ходай илчесе!

Сезгә телим саулык, озын гомер,
Шәхси бәхет, дөнья рәхәтен.
Шәкертләрнең тырыш,
инсафлысын.
Яхшы гамәл, Ходай рәхмәтен!

*10 нчы сыйныф укучылары.*



.

Безнең укытучы Әлфинур апа
Укыта әдәбият, татар телен.
Сабак бирә ул безгә
Иң матур - ана телен.

Тыңламый кара безнең укытучыны,
Бер нәрсә дә белми калырсың,
Үзеңнең ана телен белмәсәң
Авызыңны ачып утырырсың.

*8 нче сыйныф укучылары.*



Венера апа!
Өмет һәм мәхәббәт
Саласыз Сез безнең йөрәккә.
Һәр сүзегез, акыл киңәшегез
Зур ышаныч безгә терәккә

Венера апа!
Сездән өйрәнәбез туган телне,
Туган җиребезне сөяргә.
Безгә әйткән изге теләкләрнең
Кирәклеген тойдык укуда.


*11 нче сыйныф укучылары*



Рус телен без өйрәнәбез,
ЕГЭ мәҗбүри, чөнки.
Тормыш итә башлагач та,
Кирәк булырга мөмкин.

Сәвия апа рәхмәт Сезгә,
Ике телле иттегез.
Хөрмәтебез билгесе итеп,
Шигырь кабул итегез.

*6 нчы сыйныф укучылары*



Бәйрәм белән сезне, укытучыбыз!
Йөрәгебезнең якын кешесе,
Барысы өчен рәхмәт әйтеп,
Язабыз бу шигыребезне!

Авыр чакта ярдәм кулы сузып,
Гел беренче булып киләсез.
Матур сүзләр әйтеп,
Безне сөендерәсез.

Эльвира Апа кебек укытучы,
Юк сыман бу дөньяда.
Аңа карап бездә,
Тырышабыз тагында.

Сезгә телибез саулык, озын гомер,
Шәхси бәхет, дөнья рәхәтен.
Шәкертләрнең тырыш, инсафлысын.
Яхшы гамәл, Ходай рәхмәтен!

*9 нчы сыйныф укучылары*



Рәхмәт Сезгә, рәхмәт чын күңелдән,
Безне балагыздай күргән өчен.
Безнең хисләр белән янып яшәп,
Күңелләргә шатлык биргән өчен.

*5 нче сыйныф укучылары*